КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 сентябрь г.Казань № 810

2019 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны;

Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын – аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны;

Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарга төзәтү коэффициентларын.

2. 2019 елда Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмалары тулай торакларында студентлар яшәүгә норматив чыгымнар бер кешегә 1 елга 2 555 сум тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге каралары үз көчен югалткан дип санарга:

«2018 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмалары аспирантурасында югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программаларын – фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 691 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмалары аспирантурасында югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программаларын – фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2017 ел, 18 сентябрь, 691 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарга төзәтү коэффициентларына үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 13 июнь, 468 нче.

4. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 21 сентябрь, 810 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыруга

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Әзерлек (белгеч-лек) юнәлеше коды | Әзерлек (белгечлек) юнәлеше исеме | Бер кешегә югары белем бирүнең мәгариф программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар, 1 елга сум | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | әзерлек программалары буенча белем бирүнең көндезге формасы | | | әзерлек программалары буенча читтән торып белем бирү формасы | | әзерлек программалары буенча белем бирүнең кичке формасы | |
| | | специа-литет | бакалав-риат | магистра-тура | специа-литет | бакалав-риат | специа-литет | бакалав-риат |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 38.03.01 | Икътисад | | 39 672 | | | 9 773 | | |
| 15.03.04 | Технологик процессларны һәм җитештерүләрне автоматлаш-тыру | | 52 975 | | | | | |
| 38.03.02 | Менеджмент | | 38 588 | | | 8 194 | | |
| 15.03.05 | Машина төзелеше җитеш-терүләрен конструкторлык-технологик яктан тәэмин итү | | 50 650 | | | | | 19 790 |
| 21.03.01 | Нефть-газ эше | | 48 356 | | | 8 307 | | 19 006 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 13.03.01 | Җылылык энергетикасы һәм җылылык техникасы | | 49 153 | | | | | |
| 15.03.02 | Технологик машиналар һәм җиһаз | | 50 406 | | | | | |
| 13.03.02 | Электр энергетикасы һәм электр техникасы | | 50 088 | | | 8 689 | | |
| 21.04.01 | Нефть-газ эше | | | 100 849 | | | | |
| 15.04.04 | Технологик процессларны һәм җитештерүләрне автоматлаштыру | | | 98 389 | | | | |
| 38.04.01 | Икътисад | | | 76 198 | | | | |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 21 сентябрь, 810 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын – аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын тормышка ашыруга
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Әзерлек (белгеч-лек) юнәлеше коды | Әзерлек (белгечлек) юнәлеше исеме | Бер кешегә аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар, 1 елга сум | |
|---|---|---|---|
| | | фәннәр кандидатын әзерләү программалары буенча белем бирүнең көндезге формасы | фәннәр кандидатын әзерләү программалары буенча читтән торып белем бирү формасы |
| 12.06.01 | Фотоника, приборлар төзү, оптик һәм биотехник системалар һәм технологияләр | 48 490 | 17 536 |
| 21.06.01 | Файдалы казылмалар геологиясе, разведкасы һәм аларны эшкәртү | 53 779 | 16 679 |

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 21 сентябрь, 810 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы югары белем бирүче мәгариф оешмаларында югары белем бирүнең мәгариф программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарга
ТӨЗӘТҮ КОЭФФИЦИЕНТЛАРЫ

| Т/с | Учреждение исеме | Төзәтү коэффициенты |
|---|---|---|
| 1. | «Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институты» югары белем бирүче дәүләт автоном мәгариф учреждениесе | 1,195291 |
| 2. | «Әлмәт дәүләт нефть институты» югары белем бирүче дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе» | 1,318656 |

_______________